КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2026 ел, 28 гыйнвар | г.Казань | № 49

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 30 март, 241 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Ш.Х.Биктимеров исеме «Казан театр училищесы (техникум)» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирүче «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 13 апрель, 293 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2018 ел, 20 февраль, 101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) югары белем бирүче «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Түбән Кама тарнспорт инфраструктурасы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 28 апрель, 350 нче карары

белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Габдулла Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.

«Аксубай универсаль технологияләр техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.

«Буа ветеринария техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 6 июль, 546 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составына, дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«А.П.Вязьмин исемендәге Бөгелмә медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2013 ел, 19 август, 571 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы; 2020 ел, 29 декабрь, 1217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластеры составына, икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. «Югары нефть мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» югары белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе.».

6. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе» федераль дәүләт белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 22 апрель, 320 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы карарының 9, 14 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 21 май, 334 нче карарының 6, 13 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 20 май, 333 нче карарының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче карарының 8 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче карарының 10 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче карарының 10 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 20 февраль, 101 нче карарының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы карарының 3 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин